ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** / **КАРАР**

20.12.2022 г. Казань № 767-291/тп-2022

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан челтәр оешмаларының электр челтәрләренә энергия кабул итү җайланмаларын һәм (яки) микрогенерация объектларын технологик тоташтырганда таләп ителә торган максималь егәрлекнең 1 кВт өчен 2023 елга ташламалы ставкалар билгеләү турында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасы өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 20 декабрендәге 45-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Максималь егәрлеге 15 кВт артмаган (әлеге тоташтыру ноктасына элегрәк тоташтырылган энергия кабул итү җайланмаларын исәпкә алып) һәм ышанычлылыгы буенча өченче категориягә кертелгән (электр энергиясе белән тәэмин итүнең берәр чыганагы буенча), көчәнеш дәрәҗәсе 0,4 кВ һәм аннан түбәнрәк булган челтәр оешмасының электр челтәрләре хуҗалыгы объектларына тоташтырыла торган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыру максатларында гариза биргән мөрәҗәгать итүче – физик зат өчен, мөрәҗәгать итүче кишәрлеге чикләреннән мөрәҗәгать итүче өчен кирәкле булган, үзенә карата гариза бирелгән челтәр оешмасының көчәнеш классына кадәр иң якын электр челтәре объектына кадәрге аралык шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 300 метрдан артмаган һәм авыл җирлегендә 500 метрдан артмаган шарт белән, сорала торган максималь егәрлекнең һәр кВт өчен (өстәмә хак салымын исәпкә алып) 4 300,00 сум күләмендә ташламалы ставка билгеләргә.

2. Микрогенерация объектларын (энергия кабул итү җайланмаларын һәм

микрогенерация объектларын берьюлы тоташтыру максатларында мөрәҗәгать итүче – юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан гариза бирелгән очраклардан тыш) технологик тоташтыру максатларында гариза биргән мөрәҗәгать итүче өчен, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләр – физик затларның максималь егәрлеге 15 кВт артмаган (әлеге тоташтыру ноктасына элегрәк тоташтырылган энергия кабул итү җайланмаларын исәпкә алып) һәм ышанычлылыгы буенча өченче категориягә кертелгән (электр энергиясе белән тәэмин итүнең берәр чыганагы буенча), көчәнеш дәрәҗәсе 0,4 кВ һәм аннан түбәнрәк булган челтәр оешмасының электр хуҗалыгы объектларына тоташтырыла торган энергия кабул итү җайланмаларын һәм микрогенерация объектларын берьюлы технологик тоташтырганда, мөрәҗәгать итүче кишәрлеге чикләреннән мөрәҗәгать итүче өчен кирәкле булган, үзенә карата гариза бирелгән челтәр оешмасының көчәнеш классына кадәр иң якын электр челтәре объектына кадәрге аралык шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 300 метрдан артмаган һәм авыл җирлегендә 500 метрдан артмаган шарт белән, сорала торган максималь егәрлекнең һәр кВт өчен (өстәмә хак салымын исәпкә алып) 4 300,00 сум күләмендә ташламалы ставка билгеләргә.

3. Җан башына исәпләгәндә уртача кереме «Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы федераль законның 4 статьясы нигезендә билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән азрак булган аз керемле гаилә әгъзасы (ялгыз яши торган гражданин), шулай ук «Ветераннар» турында 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы федераль законның 14-16, 18 һәм 21 статьяларында, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясында, «Чернобыль АЭС һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе законының 14 статьясында, «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясында, «Россия Федерациясенең закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең кайбер закон актларын көчен югалткан дип тану турында» 2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы федераль законның 154 статьясының 8 өлешендә, «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм «Тичә» елгасына радиоактив калдыклар ташлану нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы федераль законның 1 статьясында, Россия Федерациясе Югары Советының «Чернобыль АЭС һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» РСФСР законы гамәлен аеруча хәтәрлек бүлекчәләрендәге гражданнарга кагылдыру турында» 1991 елның 27 декабрендәге

2123-1 номерлы карарының 1 пунктында һәм 2 пунктының дүртенче абзацында, Россия Федерациясе Президентының «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 1992 елның 5 маендагы 431 номерлы указында күрсәтелгән затлар тарафыннан шартнамә төзегәндә, әлеге карарның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән объектларны технологик тоташтырганда сорала торган максималь егәрлекнең һәр кВт өчен (өстәмә хак салымын исәпкә алып) 1 064 сум күләмендә ташламалы ставка билгеләргә.

4. Микрогенерация объектларын һәм максималь егәрлеге 150 кВт артмаган (әлеге тоташтыру ноктасына элегрәк тоташтырылган энергия кабул итү җайланмаларын исәпкә алып), ышанычлылыгы буенча өченче категория буенча 0,4 кВ һәм аннан түбәнрәк дәрәҗәдә челтәр оешмасының электр челтәрләре хуҗалыгы объектларына тоташтырыла торган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыру өчен берьюлы технологик тоташтыруга гариза бирелгән очракта, әлеге энергия кабул итү җайланмаларыннан һәм (яки) микрогенерация объектларыннан гамәлдәге челтәр оешмаларының электр челтәрләре хуҗалыгы объектларына кадәрге аралык шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 200 метрдан артмаган һәм авыл җирлегендә 300 метрдан артмаган шарт белән, юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен сорала торган максималь егәрлекнең һәр кВт өчен (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) 4 300,00 сум күләмендә түләү билгеләргә.

5. Әлеге карарның 1 - 4 пунктларында билгеләнгән ташламалы ставкалар 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

6. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан челтәр оешмаларының электр челтәрләренә энергия кабул итү җайланмаларын һәм (яки) микрогенерация объектларын технологик тоташтырганда таләп ителә торган максималь егәрлекнең 1 кВт өчен ташламалы ставкалар билгеләү турында» 20.07.2022 № 106-54/тп-2022 карарын 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач гамәлгә керә.

Рәис А.С.Груничев